СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

14.12.2021 № 15/4
На №__________ от______________

# КАРАР

**«Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында нигезләмә»гә үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 22 статьясы, 2013 елның 25 июнендәге 50-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасының муниципаль хезмәт турында кодексының 26 статьясы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы 182 номерлы карары (2018 елның 24 апрелендәге 281 номерлы, 2018 елның 14 июнендәге 481 номерлы, 2018 елның 17 октябрендәге 940 номерлы, 2018 елның 29 декаберендәге 1320 номеры, 2020 елның 6 августындагы 658 номерлы, 2021 елның 17 ноябрендәге 1087 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән), Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 29 декабрендәге 1320 номерлы карары, район Уставының 30 статьясы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 23 апрелендәге 25/6 номерлы карары белән расланган «Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында нигезләмә»гә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны кушымтадагыча яңа редакциядә бәян итәргә;

3.2 пунктына түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының ул электән биләгәнгә караганда югарырак төркеменә кергән муниципаль хезмәт вазыйфасына билгеләнгән очракта, ул биләгән вазыйфа кергән вазыйфалар төркеме өчен беренче класс чинын биргәнчегә кадәр класс чины өчен аның оклад күләмен исәпләү 3 процентка тигез булган вазыйфаи окладка процент ставкасыннан чыгып башкарыла.

Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфаларының ул электән биләгәнгә караганда түбәнрәк төркеменә кергән муниципаль хезмәт вазыйфасына

билгеләнгән һәм аңа электән биләгән вазыйфа буенча класс чины бирелгән очракта, класс чины өчен оклад күләмен исәпләү 7 процентка тигез булган вазыйфаи окладка процент ставкасыннан чыгып башкарыла.».

2. Әлеге карар 2021 елның 4 октябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы
Совет Рәисе

Ф.М. Камаев

«Тукай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Советының 2021 елның 14 декабре 15/4 номерлы карарына кушымта

## Тукай муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү турында нигезләмә

2. Муниципаль хезмәткәрләрнең, муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүгә бәйле рәвештә, вазыйфаи окладларын билгеләргә:

| Вазыйфа исеме | Айлык вазыйфаи оклад күләме (сумнарда) |
|---|---|
| Башкарма комитет Җитәкчесе | 34 494 |
| Совет аппараты Җитәкчесе | 31 850 |
| Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары | 31 850 |
| Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары | 31 275 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе (Финанс бюджет палатасы, Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы) | 31 160 |
| Башка җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары | 28 286 |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) | 23 686 |
| Мөстәкыйль бүлек башлыгы (мөдире) урынбасары | 19 547 |
| Район Башлыгы ярдәмчесе | 19 547 |
| Баш белгеч | 17 477 |
| Әйдәп баручы белгеч | 16 443 |
| Башка җирле үзидарә органының әйдәп баручы белгече | 16 443 |
| 1 категорияле, 2 категорияле белгеч, белгеч | 14 718 |

СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

14.12.2021 № 15/5

На № ________ от ____________

# КАРАР

**Тукай муниципаль районы Социаль-икътисадый үсеш фондының Попечительләр советы составына үзгәрешләр кертү турында**

Кадрлар үзгәреше белән бәйле рәвештә, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Тукай муниципаль районы Социаль-икътисадый үсеш фондының Попечительләр советы составыннан чыгарырга:

Шафикова Гөлнара Ауезхан кызын;
Авзалов Ленар Гаяз улын.

2. Тукай муниципаль районы Социаль-икътисадый үсеш фондының Попечительләр советын түбәндәге составта билгеләргә:

| | |
|---|---|
| Закиров Рөстәм Илдус улы | Тукай муниципаль районы Башлыгы урынбасары; |
| Галишина Гөлназ Рәис кызы | Тукай муниципаль районы Советы аппараты җитәкчесе; |
| Хәбибуллин Айрат Рафак улы | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе; |
| Яббаров Ильмир Назиф улы | Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең икътисад һәм эшмәкәрлекне үстерүгә ярдәм итү буенча беренче урынбасары; |
| Сафина Резеда Хасият кызы | Тукай муниципаль районы Советы депутаты, Иске Абдул авыл җирлеге башлыгы. |

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны бюджет, салымнар һәм икътисадый сәясәт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе

Ф.М. Камаев